ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
АЛБАЙСКОГО СЕЛЬСКОГО
ПОСЕЛЕНИЯ МАМАДЫШСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Центральная, д.28, с. Албай,
Мамадышский район,
Республика Татарстан, 4221776

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ АЛБАЙ АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ
Үзәк ур., 28 нче йорт, Албай авылы,
Мамадыш районы,
Татарстан Республикасы,422176

тел.(факс): (85563) 3-05-08; e-mail: Alb.Mam@tatar.ru, www:mamadysh.tatarstan.ru

Постановление
"22 " декабрь 2017 ел

Карар
№ 10

Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Албай авыл җирлеге территориясендә көнкүрештә кулланылган һәм яраксызга әйләнгән тererекөмешле лампаларны беренчел җыю һәм урнаштыру урыннары исемлеге турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы, «Әйләнә-тирә мохитне саклау турында» 2002 елның 10 гыйнварындагы 7-ФЗ номерлы, «Җитештерү һәм куллану калдыклары турында» 1998 елның 24 июнендәге 89-ФЗ номерлы федераль законнарга таянып, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2010 елның 3 сентябрендәге 681 номерлы карары белән расланган «Яктырту җайланмалары, электр лампалары өлешендә җитештерү һәм куллану калдыклары белән эш итү, аларны тиешенчә җыю, туплау, куллану, зарарсызландыру, транспортлау һәм урнаштыру, гражданнарның тормышына, сәламәтлегенә, хайваннарга, үсемлекләргә һәм әйләнә-тирә мохиткә зыян китерергә мөмкин булган җитештерү һәм куллану калдыклары белән эш итү кагыйдәләренең 8 пункты, Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы «Албай авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә КАРАР БИРӘМ:

1. Әлеге карарга кушымта булып килүче Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Албай авыл җирлеге территориясендә көнкүрештә кулланылган һәм яраксызга әйләнгән тererекөмешле лампаларны беренчел җыю һәм урнаштыру урыннары исемлеген расларга.

2. Эшкәртелгән терекөмешле лампаларны беренчел җыю һәм урнаштыру урыннары исемлеге турында мәгълүматны урнаштыру түбәндәгечә башкарыла дип билгеләргә:

Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Албай авыл җирлегенең түбәндәге адреслары буенча урнашкан махсус мәгълүмат стендларында:

1. Татарстан Республикасы, Мамадыш муниципаль районы, Албай авылы, Узәк урам, 28 йорт;

2. Татарстан Республикасы, Мамадыш муниципаль районы Зур Арташ авылы,Жину урамы, 19 а йорт;

3. Татарстан Республикасы, Мамадыш муниципаль районы, Югары Эрнэш авылы, Берсут урам, 24 йорт,;

Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районының рәсми сайтында http://mamadysh.tatarstan.ru веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә, шулай ук кулланылган һәм яраксызга әйләнгән тererекөмешле лампаларны беренчел жыю һәм урнаштыру урыннарында урнаштырыла дип билгеләргә.

3. Әлеге карар Мамадыш муниципаль районының http://mamadysh.tatarstan.ru рәсми сайтында, Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) рәсми басылып чыккан көннән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Татарстан Республикасы
Мамадыш муниципаль районы
Албай авыл җирлеге
башкарма комитеты җитәкчесе /И.П. Крешков/

Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Албай авыл җирлеге Башкарма комитетының
22 декабрь 2017 ел, № 10 карарына кушымта

**Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Албай авыл җирлеге территориясендә көнкүрештә кулланылган һәм яраксызга әйләнгән тererекөмешле лампаларны беренчел җыю һәм урнаштыру урыннары исемлеге**

| № | Көнкүрештә кулланылган һәм яраксызга әйләнгән теререкөмешле лампаларны беренчел җыю һәм урнаштыру урыннары исемлеге адреслары |
|---|---|
| 1. | 422176, Татарстан Республикасы, Мамадыш районы, Албай авылы, Узэк урам, 36 йорт (ярдәмче бина). |